**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

25 июль 2024ел. — № 355

**Әтнә муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган Күчемсез һәм күчемле милеккә түләүне бүлеп бирү срогын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемле һәм күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты карар итә:

1. Әтнә муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алынган арендага алынган милек өчен түләүне бүлеп бирү вакыты күчемсез милек өчен биш ел һәм күчемле милек өчен өч ел тәшкил итә.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә арендага алынган күчемсез һәм күчемле милеккә рассрочка срогын сайлау хокукы арендага алынган милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яки урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкчесе — А. Ф. Каюмов